КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 18 март г.Казань № б-450

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 23 август, б-1559 нчы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 12 декабрь, б-2586 нчы; 2015 ел, 24 август, б-1869 нчы; 2016 ел, 3 февраль, б-137 нче; 2016 ел, 30 июнь, б-1314 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, б-2866 нчы; 2020 ел, 17 гыйнвар, б-57 нче; 2022 ел, 7 июль, б-1384 нче; 2025 ел, 25 март, б-614 нче боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшләве буенча ведомствоара комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Ведомствоара комиссия составыннан Д.А.Лопаревны, Д.В.Лулаковны, М.А.Насыйровны, И.Н.Нугумановны, Е.Т.Сәгъдиевны, А.Р.Хәйруллинны чыгарырга;

Ведомствоара комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Габдрахманов Булат Фәнил улын | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасарын, Ведомствоара комиссия рәисе урынбасарын |
| Новиков Янис Александровичны | «Татарстан Республикасы Цифрлы трансформация үзәге» дәүләт казна учреждениесенең дәүләт мәгълүмат ресурсларын һәм сервисларны үстерү бүлеге башлыгын – проектлар җитәкчесен, Ведомствоара комиссия секретарен |
| Гыйниятуллин Илшат Тәлгать улын | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасарын |
| Ефремов Андрей Анатольевичны | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасарын |
| Сафронов Михаил Владимировичны | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының штаб башлыгын (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Семенов Руслан Геннадьевичны | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры урынбасарын; |

Илья Сергеевич Начвинның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры, Ведомствоара комиссия рәистәше»;

Андрей Иванович Рюховның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин